ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» август 2019 ел № 596

**Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алуны оештыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче мәктәпкәчә гомуми, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алуны гамәлгә ашыру максатында, Россия Федерациясе Конституциясенә, 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы 273-ФЗ номерлы Федераль законның 5нче статьясына, 9нчы статьясының 6 нчы пунктына, 1998 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында "гы 124-ФЗ номерлы Федераль законга, 1999 елның 24 июнендәге «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлегенә һәм хокук бозуларына профилактика үткәрү системасының нигезләре турында»гы 120-ФЗ номерлы Федераль законга, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә учреждениесенең гомуми принциплары турында "гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына таянып, Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР бирә:

1. Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алуны оештыру турындагы Нигезләмәне расларга (Кушымта).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р. И. Гарифҗанов

Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның « 05 » августында 594 номерлы карарына кушымта

**Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алуны оештыру турында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы 273-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), 1999 елның 24 июнендәге «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлегенә һәм хокук бозуларына профилактика үткәрү системасының нигезләре турында»гы 120-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), 2006 елның 27 июлендәге "Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында" 149-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), 2006 елның 27 июлендәге "Персональ мәгълүматлар турында" № 152-ФЗ Федераль законннарына (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) туры китереп эшләнде.

2. Әлеге Тәртип Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче һәм һәр дәрәҗә гомуми белем алуга хокуклы балаларның еллык шәхси исәбен, ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан билгеләнгән белем алу формаларын, шулай ук балаларны исәпкә алуда катнашучы органнарның, учреждение һәм оешмаларның үзара хезмәттәшлеге тәртибен билгели.

3. Мәҗбүри гомуми белем алуга конституция белән билгеләнгән хокукларын тәэмин итү максатларында Арча муниципаль районы территориясендә яшәүчеяисә торучы (даими яисә вакытлыча) 0 дән 18 яшькә кадәрге барлык балалар яшәү (тору) урыны буенча теркәлүгә бәйсез рәвештә ел саен исәпкә алынырга тиеш.

4. Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында мәҗбүри белем алырга тиешле, әмма гомуми белем алмаучы балаларны ачыклау һәм исәпкә алу балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре арасындагы үзара хезмәттәшлек кысаларында гамәлдәге законнар нигезендә башкарыла.

5. Балаларны исәпкә алу түбәндәге органнар, учреждение һәм оешмалар белән үзара бәйләнештә тормышка ашырыла:

5.1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе.

5.2. Мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре (алга таба мәгариф учреждениеләре).

5.3.Авыл җирлекләре башкарма комитетлары.

5.4. ДАСУ«Арча үзәк район хастаханәсе» (үз вәкаләтләре чикләрендә).

5.5. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге (үз вәкаләтләре чикләрендә).

5.6. Үз вәкаләтләре чикләрендә балигъ булмаганнарның күзәтүчезлегенә һәм хокук бозуларына профилактика үткәрү системасы органнары һәм учреждениеләре:

-Арча муниципаль районы башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе;

-Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча муниципаль районы буенча бүлеге.

6. Әлеге Тәртип буенча балаларны исәпкә алу, шулай ук белем алу формалары турыда мәгълүмат Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә, аларның конфиденциальлеген тәэмин итә торган тәртиптә җыелырга, тапшырылырга, сакланырга һәм кулланылырга тиеш.

7. Балаларны һәм белем бирү фрормаларын исәпкә алуны үткәрүдә катнашучы органнар, учреждение һәм оешмалар гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балалар турында мәгълүматларның тулылыгы, дөреслеге һәм вакытында бирелүе; 2006 елның 27 июлендәге "Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында"гы 149-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), 2006 елның 27 июлендәге "Персональ мәгълүматлар турында"гы 152-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) нигезендә мәгълүмати куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен җаваплы.

## II. Хисап мәгълүматларын формалаштыру.

2.1. Мәгариф учреждениеләренең Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче һәм һәр дәрәҗәдәге гомуми белем алу хокукына ия булган балаларны һәм ата – аналар (законлы вәкилләр) билгеләгән белем алу формаларын исәпкә алу буенча органнар, учреждение һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген оештыруны Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе (алга таба-Мәгариф идарәсе) гамәлгә ашыра.

2.2. Балаларны һәм белем алу формаларын исәпкә алу Мәгариф идарәсе тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем буенча белем алырга тиешле балалар турында Бердәм мәгълүмат базасы (алга таба – Бердәм мәгълүмат базасы) булдыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.3. Балаларның дөрес һәм тулы исәбен оештыру, аларның гомуми белем алуга хокукларын тәэмин итү максатларында муниципаль мәгариф учреждениеләренә Арча муниципаль районының аерым территорияләре (микрорайоннары) беркетелә.

2.4. Бердәм мәгълүмат базасын формалаштыру чыганаклары булып түбәндәгеләр тора:

- балигъ булмаган балалар турында Арча муниципаль районы мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең эчке эшләр органнары хезмәткәрләре белән берлектә мәгариф учреждениеләренә беркетелгән участокларны тикшерү – беренчел исәпкә алу барышында алынган мәгълүматлар;

- «Арча районы үзәк хастаханәсенең» участок педиатрлары тарафыннан балалар турында, шул исәптән яшәү урыны буенча теркәлмәгән, ләкин фактта әлеге территориядә яшәүче балалар турында бирелгән мәгълүматлар;

- балаларның яшәүләрен һәм белем алуларын тикшерү турында авыл җирлекләре башкарма комитетларыннан алынган мәгълүматлар;

- Арча муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе мәгълүматлары;

- мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының быелгы яки киләсе уку елында 6 яшь 6 айга җиткән һәм гомуми белем бирү оешмаларына кабул ителергә тиешле балалар турында мәгълүматлары;

- балигъ булмаганнар эшләре комиссиясендә профилактик исәптә торучы, шул исәптән яшәү урыны буенча теркәлмәгән, әмма чынлыкта әлеге территориядә яшәүче балалар турында эчке эшләр органнарының участок уполномоченныйлары тарафыннан алынган белешмәләр.

2.5. Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренең балалар турында мәгълүматлары түбәндәге позицияләр буенча формалаштырыла:

- әлеге белем бирү учреждениесендә укучылар (1 нче кушымта);

-мөһим булмаган сәбәпләр аркасында гомуми белем бирү учреждениеләрендә даими яки системалы рәвештә дәрес калдыручылар (2 нче кушымта).

2.6. Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре турында мәгълүматлар түбәндәге позицияләр буенча формалаша:

-мәктәпкәчә белем бирү программасын үзләштерүчеләр (3 нче кушымта);

- мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүче һәм аны тәмамлаучы 1нче сыйныфка кабул ителергә тиешле балалар (4 нче кушымта).

## III. Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә белем алырга тиешле балаларны исәпкә алу эшен оештыру.

3.1.Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче мәктәпкәчә яшьтәге балаларны агымдагы исәпкә алу эшен аларга белем бирү хезмәтләре күрсәтү максатыннан ел саен оештыралар:

- мәктәпкәчә белем бирү программасын үзләштерүче балалар турында мәгълүматлар;

- мәктәпкәчә белем алу хокукына ия булган һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрмәүче балалар турында мәгълүматлар;

- мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүче һәм аны тәмамлаучы 1нче сыйныфка кабул ителергә тиешле балалар турында мәгълүматлар (ел саен 10 сентябрьгә кадәр).

3.2. Мәгариф идарәсе балалар саны исәбен түбәндәгечә алып бара:

- мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларының балаларны исәпкә алуның электрон системасындагы мәгълүматлар нигезендә урын бирү буенча мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә исәптә торучылар;

-мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү учреждениеләренә йөрүчеләр.

3.3. Мәгариф идарәсе мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында белем алырга тиешле балалар турында,аларның 3яшьтән 7 яшькә кадәргеләренең урыннар белән тәэмин ителешенә анализ ясап, мәгълүмат әзерли.

## IV. Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә белем алырга тиешле балаларны исәпкә алу эшен оештыру.

4.1. Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре ел саен гомуми белем бирү учреждениесенә беркетелгән территориядә яшәүче (даими яки вакытлыча) 0 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар турында (белем дәрәҗәләре буенча) мәгълүмат җыюны оештыралар һәм ул мәгълүматны гомумиләштерәләр. Укучылар контингенты турында гомуми мәгълүмат гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан язмача рәсмиләштерелә, учреждение җитәкчесенең имзасы һәм учреждение мөһере белән раслана һәм Мәгариф идарәсенә ел саен 10 сентябрьгә кадәр тапшырыла.

4.2. Бердәм мәгълүмат базасын булдыру һәм алып бару максатында гомуми белем бирү учреждениеләре ел саен укучыларның кайда яшәүләренә бәйсез рәвештә агымдагы исәп алуны оештыралар:

4.3. Гомуми белем бирү учреждениеләре1 нче сентябрьдән 5 нче сентябрьгә кадәрге вакыт эчендә җәйге каникуллардан соң укырга килгән укучылар исемлеге белән учреждениенең барлык укучылары исемлеген чагыштырып карыйлар.

4.4. Учреждениегә килгән яңа укучылар исемлеге учреждение җитәкчесе боерыгы белән рәсмиләштерелә, шул ук вакытта учреждениенең алфавит китабына кертелә.

4.5. Гомуми белем бирү учреждениеләре дәрескә йөрмәүчеләрне яисә мөһим булмаган сәбәпләр белән системалы рәвештә дәрес калдыручыларны һәм учетта торучы укучыларны аерым исәпкә алып бара.

4.6. Уку елы дәвамында гомуми белем бирү учреждениесенә яңа кабул ителгән яки киткән балалар хәрәкәте турында мәгълүмат һәр уку чиреге тәмамлангач һәм 10 сентябрьгә кадәр, җәйге чордагы мәгълүмат белән бергә, Мәгариф идарәсенә тапшырыла (5-7 нче кушымта).

4.7.Ел саен агымдагы елның15 сентябренә кадәр Мәгариф идарәсе Бердәм мәгълүматлар базасы мәгълүматларын белем бирү учреждениеләренә кабул итүне тикшерү йомгаклары һәм фактта әлеге уку елында укый башлаган балалар исемлеге белән чагыштыра.

4.8. Гомуми белем бирү учреждениеләре гражданнардан Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче һәм беркетелгән гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алырга тиешле балалар турында мәгълүмат кабул итүне оештыралар.

4.9. Үз балаларына белем алуга комачаулаучы һәм (яки) үз балаларын тәрбияләү һәм укыту вазыйфаларын тиешенчә үтәмәүче гаиләләр ачыкланган очракта, гомуми белем бирү учреждениесе түбәндәге гамәлләрне башкара:

- балигъ булмаганнарны укытуны оештыру өчен ата-аналар (законлы вәкилләр) белән үзара хезмәттәшлек итү буенча чаралар күрә;

- Мәгариф идарәсенә һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенә әлеге балаларны укытуны оештыру буенча күрелгән чаралар турында хәбәр итә (кайсы көннән, нинди сыйныф, укыту формасы);

- уку елы нәтиҗәләре буенча Мәгариф идарәсенә шартлы рәвештә күчерелгән яки кабат шул сыйныфта укырга калдырылган укучылар турында; гомуми белем бирү оешмасыннан чыгарылган укучылар турында, шундый хәл туган очракта, мәгълүмат бирә.

4.10. Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе гамәлдәге законнар нигезендә Мәгариф идарәсенә балаларны исәпкә алу буенча җибәрелгән белешмәләрнең дөреслеге өчен җавап бирә, учреждениедә балалар, аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) турында документларның торышын һәм аларның сакланышын тәэмин итә.

## V. Белем алу формаларын исәпкә алу.

5.1. Төп гомуми белем алган һәм унсигез яшькә җиткән укучылар, шулай ук укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) төп гомуми белем алу тәмамланганчы, баланың фикерен исәпкә алып, белем алу формаларын сайларга хокуклы.

5.2. Мәгариф идарәсе балигъ булмаган балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) һәм 18 яшькә җиткән укучылар сайлаган белем алу формаларын исәпкә алып бара (8 нче кушымта).

## VI. Балаларны исәпкә алучы учреждениеләрнең вәкаләтләре.

6.1. Мәгариф идарәсе:

- балаларны исәпкә алу буенча эшләрне оештыру һәм методик җитәкләүне гамәлгә ашыра ;
- белем бирү учреждениеләрен Арча муниципаль районының билгеле территорияләренә беркетү эшен оештыра;
- Бердәм мәгълүмат базасына кертелергә (төшереп калдырылырга) тиешле балалар турында даими рәвештә мәгълүмат кабул итүне оештыра, аңа үз вакытында төзәтмәләр кертә ( 9нчы кушымта);
- мөһим булмаган сәбәпләр белән белем бирү учреждениеләрендә дәресләргә йөрмәүче яки системалы рәвештә дәрес калдыручы балигъ булмаганнарны исәпкә алып бара;
- гомуми белем алмаган балаларны ведомство карамагындагы мәгариф учреждениеләренә урнаштыру буенча чаралар күрә;
- шартлар һәм буш урыннар булганда 0 дән 2 яшькә кадәрге мәктәпкәчә яштәге балаларны, мәҗбүри тәртиптә 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларны

урнаштыру буенча чаралар күрә. 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларның мәктәпкәчә белем алуын, шул исәптән мәктәпкәчә белем бирүнең башка формаларын куллану хисабына, контрольдә тота;
- ведомство карамагындагы мәгариф учреждениеләренең балаларга тәрбия һәм белем бирүне оештыру буенча эшчәнлеген, тәрбияләнүчеләр һәм укучылар контингентын саклау буенча чараларын контрольдә тота ;
- ведомство карамагындагы белем бирү учреждениеләренең тәрбияләнүчеләрне һәм укучыларны исәпкә алу һәм аларның хәрәкәте буенча документлар алып бару эшчәнлеген контрольдә тота;
- гамәлдәге законнар нигезендә балалар турында шәхси мәгълүматларны тиешенчә саклауны тәэмин итә.

6.2. Мәгариф учреждениесе:
- Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче һәм һәр дәрәҗәдәге гомуми белем алу хокукына ия булган 0 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларны исәпкә алу һәм хәрәкәт итү эшен оештыра, мәгариф идарәсенә әлеге Нигезләмәнең 4.1. пункты нигезендә мәгълүмат тапшыра.
- Мәгариф идарәсенә уку елы барышында һәм җәйге чорда белем бирү учреждениесеннән китүчеләр һәм (яки) кабул ителүчеләр турында хәбәр итә;
- Мәгариф идарәсенә тиешле дәрәҗәдәге белем алган укучылар саны һәм аларның алга таба укуы һәм эшкә урнашуы турында мәгълүмат бирә;
- укучыларның һәм тәрбияләнүчеләрнең белем бирү учреждениеләренә йөрүен системалы рәвештә контрольдә тота. Сәламәтлеге буенча, үз-үзен тотуы, укуы, үсеше һәм социаль яраклашуында проблемалары булган укучылар белән шәхси профилактик эш алып бара. Тәрбияләнүчеләр һәм укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) белән аңлату эшләре алып бара;
- гамәлдәге законнар нигезендә балалар турында шәхси мәгълүматларны тиешенчә саклауны тәэмин итә.

6.3. Әлеге Нигезләмәдә күрсәтелгән органнар, учреждение һәм оешмалар үз вәкаләтләре кысаларында Мәгариф идарәсенә төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү оешмаларында мәҗбүри белем алырга тиешле, ләкин гомуми белем алмый торган балалары булган гаиләләр турында үз вакытында хәбәр итә; Мәгариф идарәсенә мәгариф учреждениеләренә мәҗбүри белем алырга тиешле 0 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар турында мәгълүматлар җыюда ярдәм итә; үз вәкилләренең эшче төркемнәр составында әлеге Нигезләмә нигезендә балаларны исәпкә алу максатында үткәрелә торган рейдларда катнашуларын тәэмин итә.

Арча муниципаль районы территориясендә
яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп
гомуми һәм урта гомуми белем бирү
программалары буенча белем алырга тиешле
балаларны исәпкә алуны оештыру турындагы
Нигезләмәгә 1 нче кушымта

______________________________________
(мәгариф учреждениесе исеме)

гомуми белем бирү учреждениесендә укучы балалар турында

МӘГЪЛҮМАТ

| № п/п | Баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган көне | Сыйныфы | Адресы | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Теркәлү урыны буенча | Яшәү (тору) урыны буенча | |
| | | | | | | |

Мәктәп директоры
М.У.

_______________ _______________
(имза) (Ф.И.О.)

* Туу датасы түбәндәге тәртиптә языла: көне, ае, елы (XX..XX..XXXX).

Арча муниципаль районы
территориясендә яшәүче мәктәпкәчә,
башлангыч гомуми, төп гомуми һәм
урта гомуми белем бирү
программалары буенча белем алырга
тиешле балаларны исәпкә алуны
оештыру турындагы Нигезләмәгә
2 нче кушымта

__________________________________________________________
(мәгариф учреждениесе исеме)

дәрескә йөрмәүче яисә мөһим сәбәпләрсез системалы рәвештә дәрес калдыручылар турында
МӘГЪЛҮМАТ

| № | Баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган көне | Сыйныфы | Яшәү (тору) урыны буенча адресы | Калдырылган дәресләр саны һәм проценты | Дәрес калдыруның сәбәпләре | Күрелгән чаралар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

Мәктәп директоры ____________________ ________________
М.У. (имза) (Ф.И.О.)

* Туу датасы түбәндәге тәртиптә языла: көне, ае, елы (XX..XX..XXXX).

Арча муниципаль районы
территориясендә яшәүче мәктәпкәчә,
башлангыч гомуми, төп гомуми һәм
урта гомуми белем бирү
программалары буенча белем алырга
тиешле балаларны исәпкә алуны
оештыру турындагы Нигезләмәгә
3 нче кушымта

______________________________________________________________
(мәгариф учреждениесе исеме)

мәктәпкәчә белем бирү программасын үзләштерүче балалар турында

МӘГЪЛҮМАТ

| № п/п | Баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган көне | Адресы | | Мәктәпкәчә белем алуны тәмамлау елы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Теркәлү урыны буенча | Яшәү (тору) урыны буенча | |
| | | | | | |

Белем бирү учреждениесе җитәкчесе ________________ ______________
М.У. (имза) (ФИО)

* Туу датасы түбәндәге тәртиптә язылa: көне, ае, елы (XX..XX..XXXX).

Арча муниципаль районы
территориясендә яшәүче мәктәпкәчә,
башлангыч гомуми, төп гомуми һәм
урта гомуми белем бирү
программалары буенча белем алырга
тиешле балаларны исәпкә алуны
оештыру турындагы Нигезләмәгә
4 нче кушымта

______________________________________________

(гомуми белем бирү учреждениесе исеме)

мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүче һәм аны тәмамлаучы
1нче сыйныфка кабул ителергә тиешле балалар турында

МӘГЪЛҮМАТ

| № п/п | Баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган көне | Фактта яшәү адресы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Белем бирү учреждениесе җитәкчесе ______________________ __________________
М.У. (имза) (Ф.И.О.)

* Туу датасы түбәндәге тәртиптә языла: көне, ае, елы (XX..XX..XXXX).

Арча муниципаль районы
территориясендә яшәүче мәктәпкәчә,
башлангыч гомуми, төп гомуми һәм
урта гомуми белем бирү
программалары буенча белем алырга
тиешле балаларны исәпкә алуны
оештыру турындагы Нигезләмәгә
5 нче кушымта

______________________________________________
(гомуми белем бирү учреждениесе исеме)

гомуми белем бирү учреждениесеннән яртыеллыкта китүче укучылар турында

МӘГЪЛҮМАТ

| № п/п | Укучының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Сый-ныфы | Гомуми белем бирү учрежде-ниесеннән чыгару турын-дагы боерыкның реквизитлары | Укучы киткән гомуми белем бирү учреждениесенең исеме | Укучы киткән территория ( өлкә, район һ.б.) исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Мәктәп директоры
М.У. ______________________ ______________________
(имза) (Ф.И.О.)

Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алуны оештыру турындагы Нигезләмәгә
6 нчы кушымта

_____________________________________________
(гомуми белем бирү учреждениесе исеме)

гомуми белем бирү учреждениесенә яртыеллыкта килүче укучылар турында

МӘГЪЛҮМАТ

| № п/п | Укучының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Сыйныфы | Укучы килгән торак пункт һәм гомуми белем бирү учреждениесенең исеме | Гомуми белем бирү учреждениесенең укучыны алу турындагы боерыгы реквизитлары |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Мәктәп директоры
М.У.

_________________________ __________________
(имза) (Ф.И.О.)

Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алуны оештыру турындагы Нигезләмәгә
7 нче кушымта

____________________________________________________
(мәгариф учреждениесе исеме)

укучыларның уку елы барышында хәрәкәте турында

МӘГЪЛҮМАТ

<table>
<tr><td rowspan="3">Уку елы башына укучы-лар саны</td><td colspan="3">Килгән укучылар</td><td colspan="3">Киткән укучылар</td><td rowspan="3">Уку улы ахырына укучы-лар саны</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Барлыгы килү-челәр</td><td colspan="2">шулардан гомуми белем бирү учреждениесеннән</td><td rowspan="2">Барлыгы китүчеләр</td><td colspan="2">шулардан гомуми белем бирү учреждениесенә</td></tr>
<tr><td>Арча районыннан</td><td>Башка территориялардән</td><td>Арча районына</td><td>Башка территорияләргә</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

Мәктәп директоры ____________________ ____________________
М.У. (имза) (Ф.И.О.)

Арча муниципаль районы
территориясендә яшәүче мәктәпкәчә,
башлангыч гомуми, төп гомуми һәм
урта гомуми белем бирү
программалары буенча белем алырга
тиешле балаларны исәпкә алуны
оештыру турындагы Нигезләмәгә
8 нче кушымта.

Гаилә белеме формасында гомуми белем алу формасын сайлау турында

ИСКӘРТМӘ

2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 63нче статьясының 5нче өлеше таләпләренә туры китереп, шуны хәбәр итәм: күрсәтелгән Федераль законның 17нче статьясының 1нче һәм 3нче өлешләре, 44нче статьясысының 3нче өлештәге 1нче һәм 3нче пунктлары, 63нче статьясының 4нче өлеше нигезендә балигъ булмаган баланың ата-анасы (законлы вәкиле) буларак, минем тарафтан

________________________________________________________________________

(балигъ булмаган баланың фамилиясе, исемен, атасының исемен, туган көнен күрсәтергә)

өчен гаилә белеме формасында гомуми белем алу формасы сайланды. Белем бирү формасын һәм уку формасын сайлау турында карар баланың фикерен исәпкә алып кабул ителде.

________________________________________________________________________

(гомуми белем бирү учреждениесенең тулы исеме)

_________________________________аттестация узу планлаштырыла.

(арадаш, дәүләт йомгаклау)

Дата: «___»__________________20___ ел

Имза: ______________ /__________________/

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм: ____________

имза

Искәртмәгә кушымта итеп бирелә:

1.Бала туу турында таныклык күчермәсе.

2.Алынган белем дәрәҗәсе турында документлар (арадаш аттестацияне узу турында белешмә, төп гомуми белем турында аттестатның расланган күчермәсе һ.б.).

Арча муниципаль районы
территориясендә яшәүче мәктәпкәчә,
башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта
гомуми белем бирү программалары
буенча белем алырга тиешле балаларны
исәпкә алуны оештыру турындагы
Нигезләмәгә
9 нчы кушымта

Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларны исәпкә алуның җыелма таблицасы (18 яшькә кадәр)

| № | Филиаллары күрсәтелгән гомуми белем бирү учреждениесенең исеме | Балалар саны | | | Гаилә белеме формасында гомуми белем алу формасы сайлаучы балалар саны | Алга таба укуларын дәвам итмәүче һәм эшкә урнашмаучы гомуми белеме булмаган балалар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Башлангыч белем | Төп белем | Урта белем | | |
| | | | | | | |

Мәктәп директоры ________________ ________________
(имза) (Ф.И.О.)

М.У.